**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең Түбән Кенә авылында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 2 декабре, № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлегенең Түбән Кенә авылыда халык җыены турында карар бирә:

1. 2020 елда Балтач районы Карадуган авыл җирлеге Түбән Кенә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 450 сум күләмендә үзсалым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Яңа урамдагы юлларны төзекләндерү;
- Ю. Гагарин урамы буенча янгынга каршы гидрант һәм аңа комплектлау җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында ( pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе: Ш. В. Низамиев